# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Яңа чана.**

Раиләләрнең ишегалдында балалар бик күп. Алар бер-берсен бик яраталар, бергә төрле уеннар уйныйлар. Быел кыш зур тау ясадылар. Балалар анда көн саен шуарга киләләр. Һәр баланың чанасы бар, ә Раиләнең генә юк. Ул урамга чыккач, дуслары йөгереп киләләр дә аңа үз чаналарын бирәләр, чөнки Раиләнең дә шуасы килә.

Беркөнне Раиләнең әтисе кибеттән яңа матур чана алып кайтты. Раилә бик шатланды. Әтисе яңа чанасын саклап шуарга кушты. Раилә чанасын алып ишегалдына чыкты. Балалар: “Раиләнең дә чанасы бар!”- дип шатландылар. Үз чанасы булгач, Раиләгә бик күңелле иде, хәзер ул да көне буе чана шуа ала. Бераздан аның янына күрше малае Илдар килде.

- Раилә, чанаңны биреп тор әле, минем дә шуасым килә, - диде. Кыз аңа:

- Кит, кит! Бирмим, я ватарсың, - диде дә үзе шуа башлады, ә Илдар читкә китте. Балалар, бу сүзләрне ишеткәч:

- Ул чанасын кызгана, саран, - дип кычкырдылар. Раиләгә бик оят булды. Ул Илдар янына килде, аңа чанасын бирергә теләде. Тик малайның аңа карыйсы да, яңа чанада шуасы да килмәде. Ә Раиләгә бик күңелсез булды. Ул хәзер яңа чанага шатлана алмый иде. (176 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Күңелсез көн**

Алиягә бик күңелсез, чөнки ул өйдә берүзе. Курчаклары белән уйныйсы да, рәсем ясыйсы да килми аның. Бүген көне буе яңгыр коя. Урамда пычрак, саз. Тузикның да оясыннан чыгасы килми, яңгырга ачуланып өрә генә. Юеш әтәч тә яңгыр астында озак йөри алмый, сарайга ашыга. Алия әнисен эштән озак көтте. Кинәт аның колагына урамнан балалар тавышы ишетелә башлады. Алар мәктәптән кайталар иде. Укучы балалар нинди бәхетлеләр!

Тагын өч елдан Алия дә алар кебек мәктәпкә йөри, анда укый, яза башлар, яхшы укучы булыр. Ә бүген аңа бик күңелсез иде. Алия тәрәзәдән Илдарны күрде, Илдар күрше малае Айдар белән бер класста укый, элек алар мәктәпкә гел бергә баралар, мәктәптән дә гел бергә кайталар иде. Менә өч көн инде Илдар мәктәпкә берүзе бара, берүзе кайта. Айдар кайда икән? Әллә авырыймы, яки теше сызлый микән? Алия тиз генә пәлтәсен киде дә урамга чыкты. Ул Илдар янына йөгереп килде дә:

- Иртәгә айдар абый урынына синең белән мәктәпкә мин йөри башлыйм, ярыймы? – диде. (156 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Энесенә ул апа**

Дүртенче класста гына укыса да Гүзәл инде апа кеше. Аның үзе шаян, үзе шук Илнур исемле энесе бар. Түгәрәк йөзле, тып-тып басып йөрүче шул малай яратып, якын итеп “Гүзәл апа” дип дәшә аңар.

Апалы-энеле ике туган бик тату, бик дус яшиләр. Һәркөнне иртән әниләре белән берсе - мәктәпкә, икенчесе - бакчага бара. Күп тә түгел, аз да түгел- көн озынына гына аерылышып торалар югыйсә. Әмма сагынышырга өлгерәләр. Өйгә кайткач, Гүзәле Илнурга мәктәптә күргәннәрен, нинди дәресләр булганын, нинди билгеләр алганын сөйләсә, энесе, апасына бакчада үзе уйнаган аю малайлары, төлке кызлары турында тәтелди. Аларның әллә нинди кызык хәлләр турында сөйләшүләрен әйтеп кенә бетererлекмени соң?! Еш кына энесен бакчадан Гүзәл үзе кереп ала. Кайчак әнисе белән әтисе я эштә тоткарлана, я кибет аркылы узасы була.

Бүген дә Илнурны бакчадан апасы алып кайтырга булды. Үзе кебек кечкенә малайлар, кызлар белән уйнап утырган малай апасын күргәч йөгереп аның янына килде.

Энесен җитәкләп Гүзәл урамга чыкты. Акрын гына өйләренә таба атлап киттеләр. (156 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Коткарды**

Фәрит, кармакларын җыеп, китәргә кузгалган иде. Янында гына әллә нәрсәнең “чулт” итеп суга төшкәне ишетелде. Күтәрелеп караса, яр читендә генә Гөлнурның ак күлмәге кабарынып торганын күрде.

Фәрит куркып китте. Ләкин ул куркуын бик тиз җиңде. Шул вакытта ук кармак сабын җиргә ыргытты да суга сикерде. Кызны, ике кулы белән күтәреп, судан ярга алып чыкты. Шунда Гөлнур чырылдап кычкырып җибәрде. Аның авыз- борынынннан су акты. Куркыныч хәлне сизеп, кызның әбисе дә йөгереп килеп җитте. Ләкин әби бернинди дә ярдәм күрсәтә алмый иде.

Фәрит бер аягы белән җиргә тезләнде. Гөлнурны күкрәге белән тез өстенә яткырды. Бер кулы белән аның гәүдәсен тотып, икенче кулы белән җилкәсеннән йомшак кына каккалады. Шунда кыз, укшып, эчендәге суны чыгара башлады. Аннан соң Фәрит Гөлнурны чирәмгә чалкан яткырды. Үзе аңа ясалма сулыш алдырды.

Менә кыз иркен сулый башлады. Ул үксеп елап та җибәрде. Әби шатлыгыннан Фәриткә бер җылы сүз дә әйтә алмый калды.

Фәрит өенә кайтып китте. Аның бөтен җиреннән су ага. Ләкин аңа шундый рәхәт, шундый җиңел. Фәрит шатлыгыннан үзенә-үзе елмая иде. (166 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Эш үткәч, үкенүдә файда юк**

Матур җәй көне иде. Марат берүзе бакчада уйнап йөри. Ул күлмәк итәгенә вак ташлар җыйган да, әле бер, әле икенче агач янына барып, таш ата. Шулай итеп, ул кошларны куркыта. Агачларга таш тидерә алмавына эче поша.

Менә бер кош аның баш очыннан ук очып үтте дә, ерак түгел юл кырыена барып кунды. Шулчак Марат, аңа төбәп, бер таш атып җибәрде. Таш кошның башына барып тиде. Ул шунда ук егылды һәм канатлары белән бер генә җилпенде дә үлде.

Марат тиз генә кош янына йөгереп барды. Кошның урман чикләвеге зурлыгындагы башыннан бер тамчы гына кан тамган. Ә нәни томшыгыннан яфрак корты күренеп тора.

Шунда агач башыннан бер кошның “чирик, чирик...ң” иткән тавышы ишетелде. Бу аның: “Әй тәртипсез, әдәпсез малай. Без, кошлар, бөтен кырларны, җиләк-җимеш бакчаларын корткычлардан саклыйбыз. Ә син, таш атып, бер иптәшебезне үтердең!” – диюе иде.

Маратка бик күңелсез булды. Бу эшенә ул бик үкенде. Ләкин инде эш үткән иде. Эш үткәч, үкенүдә файда юк. (156 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Гайбәт әйбәт түгел**

Безнең сыйныфта ике Лилия бар. Икесе дә бергә утыралар, икесе дә бик матур киенәләр, чиста йөриләр, әйбәт укыйлар да. Аларны һәрвакыт үрнәк итеп сөйлиләр.

Математика дәресендә бер мәсьәләне беркем дә, хәтта ике Лилия дә чишә алмады. Ә Мөслимә дигән кыз чиште, җавабы дөп-дөрес булып чыкты.

Моңа кадәр гел алдан кул күтәрә торган ике Лилия авызларын ачып калдылар. Тәнәфестә, кызларны җыеп, Мөслимә турында сөйли башладылар.

-Беләсезме безнең Мөслимәне, ул укытучы өстәле каршында утыра, һәрвакытта укытучы дәфтәреннән мәсьәләнең җавапларын чәлдерә, - ди беренче Лилия.

-Ул акыллы булып күренер өчен күзлек киеп йөри, - ди икенче Лилия.

-Ул өйдә кечкенә сеңлесен кыйный икән, үзенең эшен сеңлесеннән эшләтә.

-Ул китапханәдән алган китапта булган рәсемнәрдәге кешеләрнең күзләрен чукый.

Лилияләрнең сүзләренә күпләр ышанмады, чөнки Мөслимәнең әдәпле, тыныч кыз икәнен беләләр. Ышанучылар да табылды. Мәктәптә “Мөслимә рәсемнәрдәге кешеләрнең күзен чукый икән, кечкенә сеңлесен кыерсыта икән”, - дигән сүз китте.

Кешене начар итеп күрсәтергә тырышып, аның турында ялган яки кечкенә җитешсезлекне күпертеп сөйләү- гайбәт дип атала.

Кеше турында гайбәт сөйләү- әдәпсезлек, әхлаксызлык. Гайбәт сөйләүдән сак булыгыз! Гайбәткә юл куймагыз! (171 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Җәйге ял.**

Уку елы тәмамлангач, укучыларның җәйге ялы башлана. Җәй — елның иң җылы, иң матур вакыты, шуңа күрә каникулларыбыз күңелле үтә.

Гадәттә, июнь аенда мин авылга кунакка кайтам. Анда әбием һәм бабам яши. Мин аларга булышам: су китерәм, бакчадагы яшелчәләргә су сибәм, чүп утыйм. Авылда минем дусларым күп. Без алар белән күлдә су коенабыз, көймәдә йөрибез, балык тотабыз. Кичләрен урамда төрле уеннар уйныйбыз. Еш кына урманга барабыз һәм анда җиләк-җимеш, гөмбә җыябыз. Мин авылда булганда, анда Сабантуй бәйрәме үтә. Мин бигрәк тә ат чабышын, милли көрәш, кул көрәше, багана башына менү, чүлмәк ватуны карарга яратам. Үзем дә төрле уеннарда, спорт ярышларында катнашам.

Авылдан кайткач, мин әтием һәм әнием белән ял итәргә барам. Анда су керәм, кояшта кызынам, яңа дусларым белән аралашам, күңелле ял итәм.

Июль аенда мәктәптә җәйге практика була. Без мәктәпне яңа уку елына әзерлибез: сыйныф бүлмәләрен җыештырабыз, тәрәзәләрне юабыз, парталарны буйыйбыз, мәктәп бакчасында эшлибез. Практика 10 көн дәвам итә. (150 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Кошлар рәхмәте**

Кыр үрдәге камышлыкка оя ясаган. Ояга йомыркалар салган да бәбкә чыгарырга утырган. Шулвакыт каяндыр явыз төлке килеп чыккан. Ул кыр үрдәген йомыркалары өстеннән эләктереп алган да торып чапкан. Моны күрше абый күреп торган. Барып караса- ояда ун йомырка.

Күрше абый йомыркаларны алып кайта да тавык астына сала. Берничә көннән ун үрдәк бәбкәсе борын төртеп чыга.

Бәбкәләрне тавык җәй буе ияртеп йөри. Аларны дөнья белән таныштыра. Куркыныч булса, кыраклый. Яңгыр яуса, көн суытса, аларны канаты астына җыя.

Үрдәк бәбкәләре шулай үсә, җәй үтә. Көз җиткәч, гаҗәп хәл була. Кара тавыкның бәбкәләре җирне ташлап, һавага күтәреләләр. Канатлары белән җилпенепме – җилпенәләр. Тавык мескен кычкыра, кыраклый, әмма файда юк.

Ә күрше абыйның бу хәлгә бер дә исе китми. Ул бит чебиләрнең үрдәк булып үскәннәрен белә.

Үрдәкләр йорт өстеннән берничә тапкыр әйләнеп очалар нидер кычкыргалап куялар. Бу аларның, әлбәттә, күрше абыйга да, аларны карап үстергән кара тавыкка да шулай рәхмәт белдерүләре инде. Ә аннары бик еракка очыа китәләр. (153 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Дамир үстергән гөлләр**

Уку елы тәмамланып килә иде. Дамир белән Диләрә мәктәптән бергә кайттылар. Дамир Диләрәне төштән соң үзләренә кунакка чакырды. Диләрә керергә булды.

Дамир, кайтып, өстен алыштырды, ашады, барлык эшләрен дә бетерде. Диләрә һаман юк.Аптырагач, ул бакчага чыкты. Чәчәкләр утыртыр өчен җир йомшартты, тигезләде. Орлыкларны чәчә башлады. Шулвакыт Диләрә килеп керде.

-Нишлисең? - дип сорады.

-Чәчәк утыртам, - диде Дамир. Эш беткәч, Диләрә өйләренә кайтып китте. Ул да, Дамир кебек үк, бакчага чыгып, җирне йомшартты. Ул арада дус кызлары кереп, Диләрәне уйнарга чакырдылар... Чәчәк орлыклары түтәл янында таралып калды. Әнисе:

-Кызым, чәчәкләреңне утырт башта, - дигән иде дә, Диләрә кулын гына селтәде. Ул:

-Өлгерермен әле, башта уйнап керим, - диде.

Кич булгач кына кайтты ул. Бик арыган иде. Ашады да ятып йоклады. Иртәгесен чәчәкләр турында уйламады да.

Дамир чәчәкләренә көн дә су сипте, аларны карап торды. Чәчәкләр берсеннән – берсе матур булып үстеләр. Бакчаны ямьгә күмделәр. Көн артыннан көн үтте. Алтын көз килеп җитте. Беренче сентябрьдә Дамир, матур итеп киенеп, үзе үстергән чәчәкләрне кулына тотып, мәктәпкә килде. Диләрәгә шул чакта бик кыен булды. Нәкъ шундый матур чәчәкләрне ул да үстерә ала иде. (177 сүз) .

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Җитезкәй**

Ял көннәре иде. Өй кыегыбызга бер карлыгач килеп кунды. Әйләнә-тирәне караштыргалап очып йөрде дә эшкә кереште. Башта оя өчен уңайлы урын сайлады. Ә аннары көн буе авызы белән балчык ташыды. Һәр алып кайтканны пөхтә итеп урнаштыра, беркетә барды. Кичкә таба өй кыегында кечкенә генә “мәрмәр сарай” калкып чыкты. Ләкин аннан кошчык бик үк канәгать түгел иде. Ул каядыр очып китте. Шуны гына көтеп торган чыпчык ояга кереп утырды. Күп тә үтми, авызына мамыклар кыстырып карлыгач кайтты. Оясында чит кунакны күреп, ачуы чыкты. Чыр-чу килеп аны оядан куды. Ләкин чыпчыкның чыгып китәргә исәбе юк иде шул. Аптырагач, карлыгач очып китте. Бик кызгандым мин аны. Кошчыгым башка беркайчан да безнең өй кыегына килмәс дип курыктым.

Әмма борчылуларым юкка гына булган. Озакламый карлыгач үзенең иптәшләрен ияртеп килде. Алар, барысы бергә балчык ташып, ояны томалый башладылар. Чыпчык эшне бик тиз аңлап алды. Сикереп чыкты да кычыткан арасына кереп югалды.Ә карлыгачлар рәхәтләнеп бәйрәм иттеләр.

Шушы җитезлеген күреп, карлыгачыма “Җитезкәй” дип исем дә бирдем. (160 сүз) .

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Спорт**

Дәресләрдән соң спорт белән шөгыльләнәм.Бөтен кешегә дә үзе теләгән спорт төре белән шөгыльләнергә тәкъдим итәр идем, чөнки спорт — физик яктан гына түгел, ә рухи яктан да тәрбияли. Ихтыяр көчен дә ныгыта.

Мин йөзәргә бик яратам. Бу − минем иң яраткан шөгылем. Миңа бассейнда бигрәк тә баттерфляй ысулы белән йөзү ошый. Ул брасс стиленә охшаган, тик йөзгәндә кулларны гына судан чыгарасың.

Йөзү мускулларны ныгыта һәм сулыш алуны яхшырта. Мин, йөзү белән җитди шөгыльләнә башлаганнан соң, физик яктан ныгыдым. Йөзү буенча шәһәр ярышларында катнаштым. Дөрес, югары урыннар алмадым. Әмма анысы бик үк мөһим дә түгел, чөнки мин спорт белән сәламәтлек өчен шөгыльләнәм.

Үземнең организмны ныгыту өстенә, мин әле спорт секциясенә йөри башлагач тапкан дусларым белән аралашудан да тәм табам. Без барыбыз да сәламәт яшәү рәвеше алып барабыз, кайбер безнең яшьтәшләр кебек тәмәке тартмыйбыз, сыра һәм башка исерткеч эчемлекләр эчмибез. Бу начар гадәтләр − йөзүченең иң явыз дошманнары. Тәмәке тарткан кеше яхшы итеп йөзә алмый. (152 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

# 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Итәгатьле мәче**

Шулай беркөнне Чыпчык малае ишегалдына очып төшкән дә бодай чүпләргә тотынган, ди. Чыпчык, сикерә-сикерә, бодай бөртеге чүпли, ә хәйләкәр Мәче бер читтән моны күзә теп тора икән. Шулай карап-карап торган да Мәче, ялт сикереп, Чыпчыкны канатыннан эләктереп алган.

– Менә хәзер рәхәтләнеп тамак ялгыйм! – дип мырлаган Мәче.

– Нишлисез, Мәче әфәндем? Әллә чынлап та мине ашамакчы буласызмы? – дип чыркылдаган Чыпчык.

– Ашамыйча, тагын нишлим мин синең белән? Хәзер кабам да йотам! – дигән дә Мәче Чыпчыкның муенын авы зына капкан.

– Оятыгыз бармы сезнең, Мәче әфәнде? – дип өзгәләнә-өзгәләнә чыркылдаган Чыпчык. – Юынмаган килеш кем ашарга утыра инде? Хуҗагызның юынмыйча ашаганын күр гәнегез бармы?

– Монысы дөрес инде, – дип, Мәче йомшак тәпие белән битен юарга тотынган. Мәче тырнагыннан ычкынган Чыпчык канатларын җил пегән дә очып киткән. Мәченең моңа бик тә ачуы килгән билгеле.

– Болай булмый бу. Бүтән мине алдый алмассың! – дип, тешләрен шыгырдаткан ул. – Кешеләр теләсә нишләсен, ә мин башта ашыйм, аннары гына битемне юам.

Шушы көннән башлап мәчеләр ашап туйгач кына битләрен юалар, ди. (157 сүз).

# 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Йортыбыз, фатирыбыз**

Без гаиләбез белән Яр Чаллы шәһәрендә яшибез. Безнең йортыбыз Яңа шәһәрдә, Тынычлык проспектында, җиденче комплекста урнашкан. Без уңайлы урында яшибез: автобус тукталышы якын, сәүдә йортлары, кибетләр күп, базар ерак түгел.

Безнең йортыбыз тугызкатлы, яңа түгел. Фатирыбыз алтынчы катта урнашкан. Ул өчбүлмәле. Безнең фатир зур, якты, матур, чиста һәм уңайлы.

Алгы бүлмә (прихожая) кечкенә. Анда көзге, кием шкафы, аяк киеме киштәсе бар. Идәндә кечкенә палас ята. Кухня бик зур түгел, ләкин уңайлы. Анда аш өстәле, урындыклар, савыт-саба шкафы, газ плитәсе, суыткыч бар. Кухняда әнием тәмле ашлар пешерә, мин әниемә савыт-саба юарга булышам.

Залда уң якта стенка тора. Стенка белән тәрәзә арасында телевизор. Сул якта стенка каршында йомшак диван һәм ике кресло бар. Бүлмә уртасында идәндә келәм, ә түшәмдә матур люстра эленеп тора. Тәрәзә төбендә матур гөлләр үсә. Минем бүлмәмдә җиһаз күп түгел. Быел миңа яңа карават һәм компьютер алдык. Китап шкафында русча, татарча китаплар, төрле сүзлекләр, энциклопедияләр күп.

Безнең өйдә бик җылы, кышын да тәрәзәләрне ачабыз. Фатирыбыз миңа бик ошый. (159 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**

## 1 нче этап.

**Текстны укы.**

**Сабан туе**

Сабан туе – татар халкының яраткан иң матур милли бәйрәме. Бу бәйрәм, язгы кыр эшләре беткәч, җәйнең беренче ае июньдә үткәрелә. Сабан туен татарлар гына бәйрәм итми, анда руслар, чувашлар, марилар, яһүдләр һәм башка халыклар да катнаша. Сабан туена күп кунаклар кайта. Бәйрәм башта авылларда, районнарда, соңрак шәһәрләрдә үткәрелә. Сабан туе табигатьнең матур җирендә үткәрелә. Бәйрәмгә балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә җыела.

Сабан туенда төрле кызыклы уеннар, ярышлар оештыралар. Мәсәлән, балалар өчен капчык киеп йөгерү, сикерү, чүлмәк вату, баганага менү кебек уеннар була. Күп кешеләргә, бигрәк тә ир-атларга ат чабышы, татарча көрәш ошый. Көрәшне балалар башлый, аннан соң үсмерләр көрәшә. Яшьләр һәм олырак кешеләр арасында җиңгән батырга зур бүләк һәм бәрән бүләк итәләр. Сабан туенда тагын атларда ярышалар, йөгерәләр. Анда балалар да, зурлар да катнаша. Әлбәттә, сабан туе җырдан һәм биюдән башка үтми. Сәхнәдә танылган җырчылар, артистлар чыгыш ясыйлар.

Чаллыда Сабан туе Чулман буенда мәйданда була. Ул иртәдән төнгә кадәр дәвам итә. Бу көнне кешеләр туганнары белән күрешәләр, күңел ачалар. Сабан туе – бик кызыклы һәм күңелле бәйрәм. (167 сүз).

## 2 нче этап.

**Текстның эчтәлеген сөйлә.**